# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 6 Закона Республики Татарстан «О градостроительной деятельности в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2021 года

**Статья 1**

Внести в статью 6 Закона Республики Татарстан от 25 декабря 2010 года № 98-ЗРТ «О градостроительной деятельности в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 12 (II часть); 2011, № 10 (I часть); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 11 (I часть); 2015, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 41 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 38 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 49 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 26 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 29 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 дополнить пунктом 3 следующего содержания:

«3) карты границ населенных пунктов (в том числе границ образуемых населенных пунктов), расположенных в границах сельских поселений, в случае, если представительным органом сельского поселения принято решение об отсутствии необходимости подготовки его генерального плана и о подготовке правил землепользования и застройки.»;

2) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. На указанных в пунктах 2 и 3 части 1 настоящей статьи картах соответственно отображаются:

1) планируемые для размещения объекты местного значения муниципального района, относящиеся к следующим областям:

а) электро- и газоснабжение поселений;

б) автомобильные дороги местного значения вне границ населенных пунктов в границах муниципального района;

в) образование;

г) здравоохранение;

д) физическая культура и массовый спорт;

е) обработка, утилизация, обезвреживание, размещение твердых коммунальных отходов;

ж) иные области в связи с решением вопросов местного значения муниципального района;

2) границы населенных пунктов (в том числе границы образуемых населенных пунктов), расположенных в границах сельских поселений, в случае, если представительным органом сельского поселения принято решение об отсутствии необходимости подготовки его генерального плана и о подготовке правил землепользования и застройки.»;

3) дополнить частью $3^1$ следующего содержания:

«$3^1$. Обязательным приложением к схеме территориального планирования муниципального района являются сведения о границах населенных пунктов (в том числе границах образуемых населенных пунктов), расположенных в границах сельских поселений, в случае, если представительным органом сельского поселения принято решение об отсутствии необходимости подготовки его генерального плана и о подготовке правил землепользования и застройки, которые должны содержать графическое описание местоположения границ населенных пунктов, перечень координат характерных точек этих границ в системе координат, используемой для ведения Единого государственного реестра недвижимости, в соответствии с требованиями, установленными федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по выработке государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере ведения Единого государственного реестра недвижимости, осуществления государственного кадастрового учета недвижимого имущества, государственной регистрации прав на недвижимое имущество и сделок с ним, предоставления сведений, содержащихся в Едином государственном реестре недвижимости.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
27 декабря 2021 года
№ 104-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан аның генераль планын әзерләүнең кирәк булмавы турында һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү хакында карар кабул ителгән очракта, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) карталары.»;

2) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән карталарда тиешенчә түбәндәгеләр чагылдырыла:

1) муниципаль районның урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге түбәндәге өлкәләргә караучы объектлары:

а) җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итүгә;

б) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына;

в) мәгарифкә;

г) сәламәтлек саклауга;

д) физик культурага һәм массакүләм спортка;

е) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өлкәсенә;

ж) муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләргә;

2) авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан аның генераль планын әзерләүнең кирәк булмавы турында һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү хакында карар кабул ителгән очракта, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре).»;

3) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан аның генераль планын әзерләүнең кирәк булмавы турында һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү хакында карар кабул ителгән очракта, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) турындагы белешмәләр муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына мәҗбүри кушымта булып тора, аларда Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрын алып бару, күчемсез милекне дәүләт кадастр исәбенә алуны, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән таләпләр нигезендә торак пунктлар чикләре урнашкан урынның график тасвирламасы, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләргә хас булган нокталарның координаталар исемлеге булырга тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 104-ТРЗ